ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» 2003 елның 11 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең «в» пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2007, № 10), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) квалификация комиссиясе әгъзасының Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда;».

## 2 статья

Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясындагы 8 өлешенең 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), «комиссия әгъзасының Россия Федерациясе гражданлыгы бетерелгәндә, ул чит ил гражданлыгы (подданлыгы) алганда» сүзләрен «комиссия әгъзасының Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда яисә ул чит ил гражданлыгы (подданлыгы) алганда» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 104-ТРЗ